**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4611**
**15.09.2020**

2020/2021 елларның
көзге-кышкы чорына җылыту
сезоны башлану турында

Тышкы һава температурасының түбәнәюе сәбәпле, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йорт бүлмәләре һәм торак йортлар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карарының 5 пункты, Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь комплексы буенча дәүләт комитетының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.6.9 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә 2020/2021 елларның җылыту сезоны башлануны 2020 елның 17 сентябреннән билгеләргә.

2. Җылылык челтәрләре һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

1) шәһәрнең социаль билгеләнештәге объектларын (гомуми белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләре, яшьләр оешмалары) җылылык белән беренче чиратта, учреждениеләрнең заявкалары нигезендә тәэмин итәргә;

2) күпфатирлы йортларның идарәче оешмалары, торак милекчеләре ширкәтләре һәм башка оешмалар белән берлектә җылылык җибәрү һәм җылылык йөрткечнең сыйфаты буенча тиешле чаралар күрергә.

3. Әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов